СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.12.2021 г.Зеленодольск № 134

Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру һәм әлеге мәсьәләне норматив-хокукый җайга салу буенча Зеленодольск муниципаль районы җирлекләре вәкаләтләрен кабул итү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 һәм 15 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә ,Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар итте:**

1. Муниципаль торак контролен, муниципаль җир контролен, автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләр үтәлешен муниципаль контрольне гамәлгә ашыру һәм күрсәтелгән мәсьәләне норматив-хокукый җайга салу буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге вәкаләтләрен кабул итәргә.

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетын муниципаль торак контролен, муниципаль җир контролен, автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләр үтәлешен муниципаль контрольне гамәлгә ашыру органы итеп билгеләү, һәм күрсәтелгән мәсьәләне норматив-хокукый җайга салу Зеленодольск муниципаль районы Советы карамагында кала.

3. Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарына муниципаль торак контролен, муниципаль җир контролен, автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләр үтәлешен муниципаль контрольне гамәлгә ашыру һәм әлеге мәсьәләне норматив-хокукый җайга салу буенча контрольдә тоту буенча вәкаләтләрне тапшыру (кабул итү) турында Зеленодольск муниципаль районы җирлекләре җирле үзидарә органнары белән килешүләр төзергә һәм әлеге килешүне закон таләпләре нигезендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру Зеленодольск муниципаль районы җирлекләре бюджетларыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бирелә торган финанс чаралары хисабына гамәлгә ашырыла.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хүокукый мәгълүмат рәсми сайтында (htpp:/pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы, Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**